ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноября 2023 года № 6

**«Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2012 елның 20 июлендәге 3 номерлы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлә торган мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 20 июлендәге 3 номерлы «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» карарына 1 нче кушымтаның 4 нче «Сатучыларга таләпләр» бүлегендә сүзләр:

«-19.01.1998 елгы 55 номерлы Аерым төр товарларны сату таләпләрен һәм кагыйдәләрен үтәргә,» төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам..

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**